СОВЕТ НИЖНЕУСЛОНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ТҮБӘН ОСЛАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** | **КАРАР**

24.09.2018 | с. Нижний Услон | 53-211

Түбән Ослан авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы
чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум
билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты нигезендә «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында», Түбән Ослан авыл җирлеге Уставының 11 нче карары, Түбән Ослан авыл җирлеге Советының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» 20.09.2018 ел, № 52-208 карары, Түбән Ослан авыл җирлеге башкарма комитетының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» 20.09.2018 ел, № 20 карары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге Советы
КАРАР ИТТЕ:

1. Түбән Ослан авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2018 елның 18 ноябренә җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

«Җирле референдумда катнашу хокукына ия авыл җирлегенең һәр кешесеннән 2019 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- Түбән Ослан авыл җирлегендә юллардагы чокырларны ямау

ӘЙЕ ЮК».

3. Әлеге карарны «Волжская новь» район газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Югары Ослан

муниципаль районының рәсми сайтында, Түбән Ослан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы. А.З. Шайдуллин